КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 11 февраль г.Казань № 92

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 ел, 31 май, 372 нче карары белән расланган Төбәк әһәмиятендәге яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 ел, 31 май, 372 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 27 февраль, 115 нче; 2017 ел, 30 ноябрь, 927 нче, 2018 ел, 10 май, 341 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк әһәмиятендәге яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

19 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары һәм җирле үзидарә органнары

тарафыннан расланган исемлек нигезендә авария-торгызу, ремонт эшләрен һәм автомобиль юлларын карап тоту буенча эшләр башкарганда кулланыла торган юл-төзелеш һәм юл-эксплуатация техникасын һәм материалларны транспортлау;»;

23 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан төбәк әһәмиятендәге автомобиль юллары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан расланган исемлек нигезендә авария-торгызу, ремонт эшләрен һәм автомобиль юлларын карап тоту буенча эшләр башкарганда кулланыла торган юл-төзелеш һәм юл-эксплуатация техникасын һәм материалларны транспортлау;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин